Балалар журналы

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Сиңа–сюрприз бүләкләр

Кадерле дускай!

Менә син янә «Салават күпере»нең чираттагы яңа санын кулыңа алдың. Хәер, аңарчы журналханә әзерләп җибәргән «күчтәнәчләр»гә игътибар иткәнсеңдер әле, шулай бит?! Бүләк-күчтәнәчләр күңелеңә хуш килгәндер, шәт? Шундый бүләк-сюрпризлар җибәреп, моннан соң да гел шулай шатландырып-сөендереп торырга уйлыйбыз сине, дускай!

«Бүләкне сорап алмыйлар», – диләр... Шулай да, син «Салават күпере»ннән тагын нинди бүләк-сюрпризлар көтәр, өмет итәр идең? Теләкләреңне әйтеп, журналханәгә хат яз, яме. Синнән шулай ук кызык-мызык мәзәкләр, шигырьләр, әкиятләр, үзең яки дус-ишләрең белән булган күңелле хәлләр турында язмалар, матур-матур рәсемнәр көтеп калабыз.

«Салават күпере» белән һәрвакыт бергә бул, дускай!



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ

© "Салават күпере", 2005 ел

Ләбиб ЛЕРОН

Августка керем барабыз...

Сау бул, июль –
Җиләкле юл!
Саумы, август –
Алмалы дус!

Сез менә безне күрегез,
Сез менә безгә карагыз! –
Кояш белән җитәкләшеп,
Августка керәп барабыз...

Баллы алма, ал баланнар
Янып тора көмеш чыктан.
Яшел алан, чәчәк тотып,
Каршыларга йөгреп чыккан!

...Августка керәп барабыз,
Җир җылысын тоеп кына,
Ярсып чапкан яшел яллы
Җәй-толпарны тыеп кына...„



Равил Фәйзуллин

шигырьләре



Җилнең сурәте нинди?

– Җилнең мөгезләре бармы?
– Бардыр. Бардыр...
Юкса, тамырлары белән
агачлар аумас иде...
– Тырнаклары?
– Бардыр. Бардыр...
Юкса, түбә калайларын
куптара алмас иде!
– Томшыгы да бардыр әле!
– Бардыр. Бардыр...
Юкса, камышлар эченә
кереп тулалмас иде.
– Канатлары?
– Бардыр. Бардыр...
Юкса, күктә болытларны
җилпеп куалмас иде!
– ...Ә рәсемгә төшерә калсаң,
кыяфәте нинди соң?
Кошмы? Берәр җанвармы?
Әллә берәр җенме соң?
– Белмим. Белмим.
Үзе, әнә, форточкадан
миңа карап ыслап тора,
Нидер әйтеп, выжлап тора...
Тик телен төшеналмыйм!
Шуңа күрә әйткәннәрен
кәгазьгә төшералмыйм...

Рәссам Алла АЙСИНА



Күрдем төрле җанварларны

Аланда ап-ак куян күрдем.
Әй чапты соң! Әй йөгерде!
Хөрлеген, аклыгын күреп,
күңелемә пакьлек иңде.

Таллыкта кызыл төлке күрдем.
Койрыклары ай-һай нинди!
Аның шома йөрешеннән
күңелемә шуклык иңде.

Урманда соры болан күрдем.
Шундый мәгърур! Шундый эре!
Аның көчле сынын күргәч,
күңелемә гайрәт керде.

Зоопаркта арслан күрдем.
Әйләнәсе читлек иде...
Күзеннән сүнгән үч күргәч,
күңелемә сагыш иңде.



* * *

Сизмәдем: ата каз өскә
килде ыслап.
«Чукыйм!» дигәндә, муенын
кыстым учлап!

Куркуын курыкмасам да,
яман кычкырдым!
Әни килгәнче муенын
тотып тордым.

Әни әйтә: «Сакланып йөр,
акыллым!» – ди.
Абый көлә: «Безнең өйнең
Гераклы!» – ди.

Гераклмы, мераклмы –
ансын белмим мин.
Малай булып, ата каздан
куркып йөрмим мин!



Габделхәй САБИТОВ

Чәчәк нигә боекты?

– Җир уянган, кызым, чәчәкләр утыртырга вакыт, – диде Әлфиянең әнисе.

Әлфия аптырап калды:

– Кайчан йоклый соң ул, әни?

– Кыш көне, мамык юрганын ябынып, кыш буена изерәп йоклый да яз җиткәч уяна. Әнә ничек тирән сулап ята! Орлык салганны гына көтә инде ул хәзер.

Әнисе җиргә чәчәк орлыклары утырта башлады.

– Әни, минем дә җиргә орлык бирәсем килә, – диде Әлфия.

Әнисе аның учына бер бөртек кашкарый орлыгы салды. Әлфия, нәкъ әнисе кебек итеп, җирне йомшартты, бармак очы белән оя ясап, чәчәк орлыгын шунда утыртты.

Озакламый аның чәчәге тишелеп чыкты, күзгә күренеп үсә башлады.

Көннәрдән бер көнне, иртән торып чыкса, сап-сары чәчәк аткан иде кашкарые. Нәкъ кояш нурлары кебек алтын-сары.

Әлфия шатланып көлде:

– Минем чәчәгемне шундый матур итеп үстергән өчен, рәхмәт сиңа, җылы җир! – диде.

Караса, чәчәгенә бал корты килеп сарылган. Әлфия куркуга калды. Узган ел аның маңгаен корт чаккан иде. Шундый авыртты, шундый сызлады! Менә хәзер кашкарыен чагарга килгән корт.

Әлфия, баскыч янында яткан камыш себеркене алып, бал кортын куып җибәрде.

Икенче көнне иртән торып чыкса, чәчәге нишләптер боегып калган иде. Башын түбән игән, керфекләрендә яшь бөртеге.

– Ни булды сиңа, кашкарыем, ник елыйсың? – диде Әлфия.

Чәчәк озак кына дәшми торды да нәзек кенә тавыш белән әйтте аннары:

– Син бал кортларын куасың, алар килмәгәч, мин серкәләнә алмыйм. Серкәләнмәгәч, көзгә орлыкларым булмас инде, – диде.

– Ә нигә кирәк соң ул орлыклар? – дип сорады Әлфия.



– Орлыклар – минем балаларым, – дип җавап бирде кашкарый. – Алдагы елда мин булмам, минем урынга алар чәчәк атар иде. Болай булгач, җирдә нәселем өзеләчәк...

Кашкарыйны кызганып, тәмам кайгыга калды Әлфия, үзенең дә керфекләренә яшь бөртекләре кунды. Тиз генә өйгә кереп кайгысын әнисенә сөйләде.

– Без аңа бал суы сибик, әни, бал кортлары яңадан килсен, – диде.

– Кирәкми, кызым, син аңа саф су гына сип, – диде әнисе. – Шулай итсәң, чәчәгеңнең һәр күзәнәгенә бал җыелыр. Ә кортларга тимә, алар чәчәкләргә бик зур файда китерәләр.

Әлфия шунда ук бакчага чыгып йөгерде, кечкенә чиләге белән су алып килеп, чәчәккә сипте.

– Рәхмәт сиңа, сусавымны бастың, – диде кашкарый.

Шунда ук, без-без безелдәп, бал кортлары килеп җиттеләр, чәчәкнең сары керфекләренә кундылар. Кашкарый, башын күтәреп, кояшка бакты һәм шатлыктан көлеп җибәрде.

Аңа карап, Әлфия дә куанып көлә иде.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Гаҗәп төш

Әниемне төштә күрдем,
Елмайды әллә кайдан.
Кар-бураннар туздырып,
Чана да шудык таудан.

Иртүк торып сөйләдем,
Хәтерләми ул чакны.

Роза КОЖЕВНИКОВА шигырьләре

Хыялда сәяхәттә

Машина күргәч, минем
Шофер буласым килде.
Кешеләрне утыртып
Чабар идем һәр көнне.


Поезд күрдем-кызыктым,
Шуны йөртәсем килде.
Келтер-келтер аннары
Әйләнәм бөтен җирне!

Очкычта очкан идем,
Күктә көмеш ай күрдем.
Уй-хыялны үзгәрттем:
«Очучы булам!» – дидем.

Зәңгәр диңгез, һай, матур!
Пароходта ял итәм.

Тизрәк, бик тиз үсим дә,
Булачакмын капитан!

Ә син кем булыр идең?
Әйтче, тизрәк, әйт инде!
Беләсем килә минем!..



Әниемә

Кояш белән сөйләшәсем килә,
Сер сөйлисем килә җилгә.
Ай белән гәпләшәсем килә.
Шул әкияттә яшисем килә,
Әнием белән бергә-бергә...

Курчак төштә ни күрә?

Яраткан курчагымны
Куйдым мендәр астына.
Миңа кергән төшләрнең
Күрсен диеп барсын да.

Сөт нигә ташый?

Кемгә бәлки гаҗәптер,
Аптырамыйм мин генә:
Сөт пешүдән курка да
Ташып китә тиз генә.

Сорау артыннан сорау


Йолдызларны кем кабыза,
Айны кемнәр яктырткан?
Йолдыз җемелди тагын
Тирән кое астыннан...
Шуларны белә алмыйча
Мин аптырап утырам.

Урысчадан
Зиннур ХӨСНИЯР
тәрҗемәләре.



Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА


Әйдәгез, уйныйбыз!



Йомшаккай, Шаянкай һәм Наянкай, берсен-берсе узышып, шаярышып уйный торгач, кич җиткәнен сизми дә калганнар. Инде өйләренә дә кайтырга вакыт. Шулай да әниләре янына кайсы беренче кайтыр икән соң?


Уенда теләгән һәркем катнаша ала. Уйнар өчен кубик һәм фишкалар (рәсемле түгәрәкләр) кирәк булачак. Фишкаларны беренче бүлем янына куеп, кубикны ташлагыз. Кубик ташлаганда ничәле сан төшсә, фишканы шул санча бүлемгә күчерергә кирәк була. Уенны чиратлап уйныйбыз. Фишка биремле түгәрәккә җитсә, җәзаны үтәми китәргә ярамый – бу уенның шарты. Үти алсаң, өч шакмак алга күчәсең, үти алмасаң – өч шакмак артка.

Әйдәгез, уенны башладык. Чү! Ә кем беренче? Санап алыйк:



Рәссам
Алла АЙСИНА

«Бер, ике, өч...
Куяннарда бөтен көч!
Дүрт, биш...
Безне җиңеп булмый һич!
Алты, җиде...
Куркаклар башын иде!
Сигез, тугыз, ун...
Алты бүре – алты тун!
Без тук бүген, бүре ач –
Әнә килә, тизрәк кач!.»






26 27 28 29 30 31 32 33 34 35 36 37 38 39 40 41 42 43 44 45 46 47

Биергә

Мәзәк сөйләргә

Нинди дә булса шигырь укырга

...надан башлагыз



Чиратыгызны буш уздырыгыз

Җыр җырлап күрсәтергә



Ләбиб ЛЕРОН

Җилкуар

Мәзәкият

Җәй бетә инде, ә минем бер көн дә җүнләп ял иткәнем юк әле...

Шундый малай инде мин — көн саен үземә бер шөгыль табып торам.

Дүшәмбе көнне иртәдән кичкә кадәр ата каз куып йөрдем. Миңа ысылдамакчы булган иде, шуңа кудым. Үземнең хәлем беткәнче чаптым артыннан. Бүтән ысылдарга җөрьәт итмәс инде...

Сишәмбе көнне, минем кем икәнлегемне ныклап исендә калдырсын дип, ата казны тагын куып йөрдем. Төшкә кадәр. Кичкә хәтле әтәч белән чиләндем. Ул да кукраеп өскә килмәкче иде чөнки. Кукраймас инде бүтән...



Чәршәмбе көнне күркәгә чират җитте. Ул да, голдыр-голдыр дип, миңа карап тора иде – көне буе эзәрлекләдем үзен. Минем күземә бүтән күренмәс инде...


Пәнҗешәмбе көнне кәҗә тәкәсенең иманын укыттым. Сөзмәкче булган иде мине. Әй эләкте дә инде малкайга! Сакалын селкетеп, каршыга килмәс инде бүтән...

Җомга көнне Акбайны кудым. Миңа өреп маташкан була. Оясыннан чыкмаслык иттем. Бүтән өрмәс инде...

Шимбә көнне яланда бозау куып йөрдем. Болай гына. Бер шөгыль булсын дип кенә...

Бүген – якшәмбе. Йөрим ишегалдында. Ни ата каз күренми, ни әтәч, ни күркә юк – барысы да каядыр качып беткән. Йөрим бер эше юк кеше кебек. Сызгырынып. Хет сыңар чыпчык та күренми – таш атып куарга.

Каян бер шөгыль табарга? Көне буе җил куып йөри алмыйм бит инде — «Җилкуар» дип кушамат тагулары бар...



Рәссам Светлана ПРИВИНА



Әлеге матур-матур рәсемнәрнең иясе – Зөһрә Муллагилова. Тумышы белән Азнакайдан. Казандагы 155 нче мәктәп-гимназиядә укый. Зөһрә Г.Тукай һәм М.Җәлил әсәрләренә иллюстрацияләр ясаган. Яшь рәссам атаклы әдипләребезнең нинди әсәрләрен күздә тотып ясады икән?









Рәсемнәр астына ни дип язар идең?

МӨҖӘҺИТ

Кызык итте

Йалт та йолт
Килә яшен.
Нигәдер
Көлә яшен.

Күкләрне
Дер селкетә.
Табигать –
Шифа көтә.


Яңгыры
Кая киткән?
Әллә соң
Кипте микән?

Тамып та
Карамады.
Нәрсәбез
Ярамады?

...Вәт яңгыр
Кызык итте:
Әйләнеп
Узып китте.

Тырма

Тырма, тырма,
тик торма!
Басып торма,
утырма!
Син шуңа да
бит – тырма.
Тырма!



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ







Ландыш ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА, 10 яшь.

Әлеге рәсемнәрне Казандагы 11 нче гимназия укучылары ясаган. Аларның кызык-сәер, гаҗәп-матур сурәтләренә игътибар ит әле, дускай!



Гөлинә ГАЛИМОВА, 10 яшь.




Миләүшә БӘДРЕТДИНОВА, 10 яшь.





– Алдашырга яратмыймын,
Юк-бар сүзләр сөйләмим:
Көнбагышлар белән бергә
Үскән малай гүя мин!
Казан.

– Иркенләп, бик җайлап
Идәнгә утырып,
«Салават күпере»н
Укыймын йотлыгып!
Мөслим, Ташлыяр.





– Эләкмәсме балык? – дип,
Утырам кармак салып...
Ни сорармын икән, дим,
Эләксә... алтын балык!
Актаныш, Татар Суыксу.



– Елмаймыйча һәм көлмичә
Торалмыймын бер дә мин...
Нур чәчүче чәчәкләр без:
Күктә – кояш, җирдә – мин!
Биектау, Өнсә.

– Озак эзләрләр микән,
Таба алырлар микән? –
Әти-әни күрмәгәндә
Качтык әле без икәү!
Чувашия,
Комсомол, Чичкан.



Ринат НУРУЛЛИН

Җиде туган-тумача

(Такмак-табышмак)

Атнада җиде туган –
Берсеннән-берсе уңган.
Базга төшеп, Дүшәмбе
Алып менгән бәрәңге.
Урап кайтып чишмәне,
Су китергән Сишәмбе.
Тырышкан Чәршәмбе дә, –
Бәрәңгене тураган.
Пәнҗешәмбе табага
Аны ваклап тураган.
Җомга үз эшен көткән –
Тоз, борыч, әнис сипкән.
Кыздырып майда, Шимбә
Бәрәңгене пешергән.
Таба төбен кырырга
Мине дә чакырдылар.
Истән чыккан Якшәмбе,
Ә ул нәрсә эшләде?!
Әзерләгән Якшәмбе
Табышмакның иң шәбен.
– Исемнәребездән, – ди, –
Уртак хәреф эзлә, – ди...
Ишеткәнемне сезгә
Түкми-чәчми җиткезәм.
Шул хәрефне табыгыз,
Миңа хатлар языгыз.

Җавап: Атна көннәренең исемнәрендә «м» хәрефе бар.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ


Гөлшат ЯРМӨХӘММӘТОВА

Табышмаклар



Үзе барын белгертми,
Беркемне өйгә кертми.

(Йозак)



Чәчләре яшел, бөдрә,
Гәүдәсе билдән җирдә.

(Кишер)




Көндез һаман йокыда,
Төнен күселәр тота.

(Песи)



Кыяклары бик яшел,
Киссәң, чыга күз яше!

(Суган)



Көне буе кыткылдый,
Кояш байгачтын йоклый.

(Тавык)

Бер дә сөйләшми, түзә,
Ә үзе суда йөзә.

(Балык)

Үлән һәм печән ашый,
Үзе белән сөт ташый.

(Сыер)





Салават күпере

7-8 (196-197) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта А.АЙСИНА рәсеме
Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmall.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 22.06.2006 ел.
Басарга кул куелды 22.06.2006 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 9585 данә. Заказ 3-503.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н. Шаһиев, Н. Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАНОВ

Салават күпере

Яңгыр явып үтүгә үк,
Балкыды күк йөзендә...
Җиде төс бар үзендә –
Салават күперендә!

Шәп журнал бар – дөньяда
Аны бик күпләр белә...
Сихри көч бар үзендә –
«Салават күпере»ндә!

